Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Иске Рязап авыл җирлеге советы

КАРАР

22.04.2024 ел № 6

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Иске Рәҗәп авыл җирлеге башкарма комитетына кабул иткән очракта:

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске Рәҗәп авыл җирлеге Советының 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Иске Рәҗәп авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карарга тәкъдим итәргә.

3. Рәсми рәвештә әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының интернет челтәрендәге рәсми сайтында - http://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм https://pravo.tatarstan.ru/ хокукый мәгълүматның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иске Рәҗәп авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Иске Рәҗәп авыл җирлеге башлыгы: М.А.Нугаев